МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.09.2021 г.Казань № 646

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 12 октябрендә 7979 номеры белән теркәлде

Өлкән яшьтәге гражданнарның (инвалидларның) чит кеше каравына индивидуаль мохтаҗлыгын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасы турында» 2021 елның 31 мартындагы 198 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021-2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 елның 13 февралендәге 77 номерлы карары белән расланган 2021-2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 2.1 пунктын гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Өлкән яшьтәге гражданнарның (инвалидларның) чит кеше каравына индивидуаль мохтаҗлыгын билгеләү кагыйдәләрен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өлкән яшьтәге гражданнарның чит кешеләр ярдәменә бәйле булуын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 16 мартындагы 167 номерлыгы боерыгы үз көчен югалткан, дип танырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Ю.И.Абдреевага йөкләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2021 елның 9 сентябрендәге 646
номерлы боерыгы белән расланды

## Өлкән яшьтәге гражданнарның (инвалидларның) чит кеше каравына индивидуаль мохтаҗлыгын билгеләү кагыйдәләре

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Өлкән яшьтәге гражданнарның (инвалидларның) чит кеше каравына индивидуаль мохтаҗлыгын билгеләү кагыйдәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге граждан-нарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасы турында» 2021 елның 31 мартындагы 198 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021-2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 елның 13 февралендәге 77 номерлы карары белән расланган 2021-2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 2.1 пунктын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

1.2. Әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган төп төшенчәләр «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасы турында» 2021 елның 31 мартындагы 198 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

### II. Типизацияне үткәрүдә катнаша торган органнар һәм учреждениеләр

Социаль хезмәтләр күрсәтелә торган өлкән яшьтәге гражданнарга (инвалидларга) типизации үткәрү түбәндәгечә башкарыла:

социаль яклау территориаль органы тарафыннан Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре (алга таба – комплекслы үзәкләр) белән берлектә – өйдә һәм ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтелә торган затларга карата, шулай ук Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының муниципаль районлагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) (алга таба – социаль яклау буенча территориаль орган) өйдә яки стационар формада яисә ярымстационар формада көндезге бүлекчәләрдә социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән өлкән яшьтәге гражданнарга (инвалидларга) карата;

Татарстан Республикасының картлар һәм инвалидлар өчен интернат

йортлары (алга таба – интернат йортлары) тарафыннан – социаль хезмәтләр күрсәтелә торган, интернат йортларында яшәүче затларга карата;

Татарстан Республикасы территориясендә психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортлары (алга таба – писхик тайпылышлары булган гражданнар өчен интернатлар) тарафыннан – әлеге учреждениеләрдә яши торган, социаль хезмәтләр күрсәтелә торган затларга карата.

## III. Типизацияне үткәрү вакыты

3.1. Чит кешеләр тәрбиясенә мохтаҗ булган, социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап социаль яклау буенча территориаль органга мөрәҗәгать иткән яисә медицина оешмасыннан, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) чит кеше каравына потенциаль мохтаҗ булуы турында мәгълүмат алынган очракта яки «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» ярдәмче системасының «Озак вакытлы карау системасы» модулендә сигнал картасы алынган очракта, өлкән яшьтәге гражданнарга (инва-лидларга) типизация үткәрүне социаль яклау буенча территориаль орган социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза (мөрәҗәгать) кабул ителгән яисә сигнал картасы алынган көннән башлап ике эш көне эчендә өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) яшәү урыны буенча комплекслы үзәк белгечләрен җәлеп итеп оештыра.

Комплекслы үзәкләрдә өйдә һәм көндезге бүлекчәләрдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтелә торган затларга, интернат йортларында, писхик тайпылышлары булган гражданнар өчен интернатларда социаль хезмәтләр күрсәтелә торган затларга типизация уздыру әлеге учреждениеләрнең администрацияләре тарафыннан оештырыла һәм планлы һәм планнан тыш типизация уздыру срокларына туры китереп, әлеге учреждениеләрнең хезмәткәрләре тарафыннан уздырыла.

3.2. Комплекслы үзәкләрдә, интернат йортларында, психик тайпылышлары булган гражданнар өчен интернатларда социаль хезмәтләр күрсәтелә торган өлкән яшьтәге гражданнарга (инвалидларга) планлы типизация түбәндәгечә үткәрелә:

алдагы типизация нәтиҗәләре буенча чит кеше каравына беренче һәм икенче мохтаҗлык дәрәҗәсенә кертелгән социаль хезмәтләр күрсәтелә торган затлар өчен елга бер тапкыр;

алдагы типизация нәтиҗәләре буенча чит кеше каравына нульле яки өченче мохтаҗлык дәрәҗәсенә кертелгән социаль хезмәтләр күрсәтелә торган затлар өчен бер ел ярымга бер тапкыр.

3.3. Планнан тыш типизация социаль хезмәтләр күрсәтелә торган затларның тормыш эшчәнлеген яхшырта яки начарайта торган шартлар (терелү, тернәкләнү, психологик торышның яхшыруы, катлаулы чирнең үсеш алуы яки хроник чирнең кузгалуы, госпитальләштерүдән соңгы чорда хирургия

тыкшынуы, социаль (гаилә) статусның үзгәрүе; якын кешене югалту, тормыш шартлары үзгәрү, сәламәтлекнең гомуми торышы күренә торып начарлану) ачыкланган очракта, чит кеше каравына мохтаҗлыкның кайсы дәрәҗәсенә кертелүенә бәйсез рәвештә уздырыла. Планнан тыш типизация әлеге шартлар ачыкланганнан соң өч эш көненнән артмаган вакыт эчендә үткәрелә.

## IV. Типизация үткәрүче белгечләргә карата таләпләр

4.1. Типизацияне тиешле әзелекне узган, социаль яклау буенча территориаль орган орган белгечләре, социаль тернәкләндерү белгечләре, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре белгечләре (алга таба – типизаторлар) үткәрә.

4.2. Типизацияне үткәрүдә кимендә ике типизатор катнаша.

4.3. Типизаторның тышкы кыяфәте гомуми кабул ителгән эш стиленә туры килергә тиеш, ул рәсмилеге, тыйнаклыгы, традиционлыгы, пөхтәлеге, дини атрибутикасы булмавы белән аерылып тора.

4.4. Өлкән яшьтәге гражданинга (инвалидка) хезмәт күрсәтә торган социаль хезмәткәр яки сиделка (карау буенча ярдәмче) тарафыннан типизация үткәрү рөхсәт ителми.

## V. Типизацияне үткәрү тәртибе

5.1. Типизация өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) торган урыны буенча (фатирда, шәхси йортта яки стационар социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә) үткәрелә.

5.2. Өлкән яшьтәге гражданинга (инвалидка) килер алдыннан типизатор телефон аша мөрәҗәгать итәргә тиеш:

өлкән яшьтәге гражданинга (инвалидка) һәм (яки) аның законлы вәкиленә яки башка ышанычлы затына типизация үткәрү өчен булачак визитның максаты турында аңлатырга һәм аның ризалыгын яки аның законлы вәкиленең яки башка ышанычлы затының типизация үткәрүгә ризалыгын алырга тиеш;

өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) (аның законлы вәкиле яки башка ышанычлы заты) белән типизацияне үткәрү өчен визит датасын һәм вакытын телдән килештерергә тиеш.

5.3. Типизация максаты белән өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) янына килгәндә, типизатор:

үзе белән таныштырырга (исеме, вазыйфасы, килү максаты), хезмәт таныклыгын күрсәтергә тиеш;

очрашуның нидән гыйбарәт булуы турында сурәтләргә тиеш;

мобиль телефонын сүндереп куярга тиеш;

мәрхәмәтле мохит булдырырга тиеш.

5.4. Өлкән яшьтәге гражданнарда (инвалидларда) когнитив тайпылышлар булган очракта, белгеч белән очрашу һәм типизацияне үткәрү өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) туганы яки өлкән яшьтәге гражданинны (инвалидны) карый торган (булган очракта) социаль хезмәткәр яки сиделка

(тәрбия буенча ярдәмче) катнашында үткәрелергә тиеш.

5.5. Өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) ишетү, күрү һәм сөйләү буенча чикләүләре булган очракта, аралашу аның туганы яки аны караучы (караган) зат катнашында үткәрелергә тиеш.

5.6. Билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез дип танылган өлкән яшьтәге гражданинга (инвалидка) типизация аның законлы вәкиле катнашында үткәрелә.

5.7. Өлкән яшьтәге гражданнарны (инвалидларны) карау социаль хезмәткәр яки сиделка (тербия буенча ярдәмче) тарафыннан гамәлгә ашырылса, типизация социаль хезмәткәр (сиделка) катнашында үткәрелә.

5.8. Өлкән яшьтәге гражданинга (инвалидка) типизация үткәрүгә ризалык бирми икән, типизатор аның максаты турында кабат аңлатырга тиеш. Типизатор тагын бер мәртәбә аңлатканнан соң да өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) типизация үткәрүдән баш тартса, аңа типизация үткәрелми, өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) типизация үткәрүдән баш тартуы турында акт төзелә.

5.9. Типизация барышында өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) социаль, шул исәптән гаилә, статусы, шулай ук тормыш эшчәнлегендәге чикләмәләрен ачыклый торган критерийлар бәяләнә.

5.10. Типизация түбәндәгеләрдән тора:

өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) яшәү-көнкүреш һәм социаль шартларын (өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) тормыш эшчәнлеге турындагы мәгълүматны (гомуми (шәхси) һәм медицина белешмәләрен) өйрәнүне үз эченә ала), яшәеш шартларын, социаль тирәлеген тикшерү, әйләнә-тирәлекне бәяләү (тормыш өчен мөһим булган социаль объектларның урнашу урыны), коммуналь-көнкүреш хезмәтләре, кирәкле көнкүреш предметларының һәм кирәк-яракларының, шул исәптән техник тернәкләндерү чараларының һәм ярдәмче чараларның булуы һәм файдаланылуы, өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) функциональ мөмкинлекләрен киметә торган фактларны тикшерү, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасында чит кеше каравына мохтаҗ булган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 елның 9 апрелендәге 209/635 номерлы уртак боерыгына (алга таба – 209/635 номерлы уртак боерык) 6 нчы кушымтадагы форма буенча торак-көнкүреш һәм социаль шартларны тикшерү актын тутыру;

209/635 номерлы уртак боерыкның 7 нче кушымтасындагы форма буенча бәяләү бланкына туры китереп, өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) белән интервью уздыру (мәҗбүриле булмаган аралашу формасында, профессиональ, конструктив рәвештә уздырыла). Өлкән яшьтәге гражданинга (инвалидка) бланкта каралган сорауларны кычкырып уку рөхсәт ителми;

өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) белгеч үтенече буенча (белгеч артыннан кабатлап) кешенең төп физиологик ихтыяҗларны мөстәкыйль гамәлгә ашыруга, көндәлек көнкүреш эшчәнлеген башкарырга, шул исәптән

шәхси гигиена күнекмәләрен куллана алу сәләтен раслый торган көндәлек базислы гамәлләрне башкаруын; бәяләү бланкы нигезендә пространствода хәрәкәт итә алуын күзәтү;

интервью һәм диагностика нәтиҗәләрен йомгаклау, бәяләү бланкын тутыру;

209/635 номерлы уртак боерыкның 8 нче кушымтасы нигезендә өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) чит кеше каравына мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләү.

5.11. Типизацияне үткәрү көнендә:

өлкән яшьтәге гражданинга (инвалидка) үткәрелгән типизация турында мәгълүмат типизатор тарафыннан «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» ярдәмче системасының «Озак вакытлы карау системасы» модуленә кертелә;

торак-көнкүреш һәм социаль шартларны тикшерү акты, бәяләү бланкы, өлкән яшьтәге гражданинга (инвалидка) билгеләнгән кеше каравына мохтаҗлык дәрәҗәсе турында (кеше каравына мохтаҗлык дәрәҗәсен үзгәртү турында) мәгълүмат, социаль яклау буенча территориаль орган тарафыннан өлкән яшьтәге гражданин-ның (инвалидның) социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булуы (гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту) турында карар кабул итү һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү яки социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын яңадан карау өчен, социаль яклау буенча территориаль органга турыдан-туры тапшырыла;

5.12. Типизация уздырылган көннән соң ун эш көне дәвамында – чит кеше каравына мохтаҗлыкның беренче-өченче дәрәҗәләре билгеләнгән социаль хезмәт күрсәтелә торган затлар өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән раслана торган форма буенча индивидуаль карау планы төзелә, ул социаль хезмәткәрләргә (карауны башкара торган персоналга) анда күрсәтелгән гамәлләрне башкару һәм үтәү өчен тапшырыла.